Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Мөслим авыл җирлеге Советы

КАРАР

2025 елның 27 марты № 59/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 27 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча түбәндәгеләрне игълан итәргә:

Мөслим ав., Пионер ур., 11 йорт (административ бина);

Мөслим авылы, Пионер ур., 10 йорт (мәдәният йорты бинасы)...

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Мөслим авыл җирлеге
башлыгы Л.З. Хәбибуллина

Чистай муниципаль районы
Мөслим авыл җирлегенең
2025 елның 27 мартындагы
59/1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № т/б | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче Центральный | Мөслим авылы<br>Первомайская урамы, 1-14 номерлы йортлар, Центральная урамы, 1-40 номерлы йортлар, Пионер урамы, 1-18 номерлы йортлар, Комсомол урамы, 1а,1,5,9,14 йортлары | 91 |
| 2 | 2 нче Комсомол | Мөслим авылы<br>Комсомол урамы, №2,3,4,6,8,10,11,12 йортлар, 13-55 нче так санлы йортлар , 18-34 нче җөп санлы йортлар, Октябрь урамы, 10-20 нче җөп санлы йортлар, 31-51 нче так санлы йортлар | 91 |
| 3 | 3 нче Октябрь | Мөслим авылы<br>Октябрь урамы, 1-29 номерлы так санлы йортлар, 2-8 номерлы җөп санлы йортлар, Школьная урамы 1-9 номерлы йортлар, 13-16 номерлы йортлар | 91 |
| 4 | 4 нче Полевой | Мөслим авылы<br>Школьная урамы, 17-26 нчы йортлар, Озерная урамы, 1-9 нчы йортлар, Полевая урамы, 1-39 нчы йортлар, Янга-Урал авылы, Лесная урамы, 1,4,8,9,10,16 нчы йортлар | 91 |
| 5 | 5 нче Колхоз | Бахта авылы, Колхоз урамы, 1-26 нчы йортлар, | 74 |
| 6 | 6 нчы Широкий | Бахта авылы<br>Широкая урамы, 2-24 нче җөп санлы йортлар, 1-21Б номерлы так санлы йортлар, Садовая урамы, 1-18 нче барлык йортлар, Овражная урамы 3 нче йорт | 74 |
| 7 | 7 нче Овражный | Бахта авылы<br>Широкая урамы 26-66 нчы җөп санлы йортлар, 23-59 нчы так санлы йортлар, Овражная урамы, 1,2 нче йортлар, 5-11 нче йортлар | 74 |

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге




